| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2021 г.Зеленодольск № 130

Төзекләндерү өлкәсендә, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салудан гыйбарәт булган, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен кабул итү турында.

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Төзекләндерү өлкәсендә, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салудан гыйбарәт булган, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен кабул итәргә . (1 нче кушымта).
2. Җирлек территориясен төзекләндерү өлкәсендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетын, норматив-хокукый җайга салу Зеленодольск муниципаль районы Советы карамагында калган, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру органы итеп билгеләргә.
3. Төзекләндерү өлкәсендә, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салудан гыйбарәт булган, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен тапшыру (кабул итү) буенча Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә һәм әлеге килешүне законнар таләпләре нигезендә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, Зеленодольск муниципаль районы бюджетларыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән башкарыла, шулай ук «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зеленодольск муниципаль районы Советы карарында каралган очракларда һәм тәртиптә үз

матди ресурсларыннан һәм финанс акчаларыннан өстәмә файдаланырга хокуклы.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хүокукый мәгълүмат рәсми сайтында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет " мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ИНН 1648017831 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

ЗМР Советының
2021 елның 17 декабрендәге
№ 130 карары буенча кушымта

.

Төзекләндерү өлкәсендә, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән һәм әлеге мәсьәләне норматив-хокукый җайга салудан гыйбарәт булган, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр тапшыручы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре исемлеге

1. Васильево шәһәр тибындагы поселогы
2. Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы
3. Әйшә авыл җирлеге
4. Акъегет авыл җирлеге
5. Бишнә авыл җирлеге
6. Олы Ачасыр авыл җирлеге
7. Большие Ключи авыл җирлеге
8. Олы Карагуҗа авыл җирлеге
9. Олы Шырдан авыл җирлеге
10. Олы Җәке авыл җирлеге
11. Күгәй авыл җирлеге
12. Күгеш авыл җирлеге
13. Мамадыш Әкил авыл җирлеге
14. Мулла Иле авыл җирлеге
15. Түбән Урысбага авыл җирлеге
16. Новопольский авыл җирлеге
17. Норлат авыл җирлеге
18. Октябрь авыл җирлеге
19. Осиново авыл җирлеге
20. Раифа авыл җирлеге
21. Рус Әҗәле авыл җирлеге
22. Свияжск(Зөя) авыл җирлеге
23. Өтәшкә авыл җирлеге